ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27 12 2023 г. № 1271

Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә торак урыны өчен түләү билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак Кодексының 14 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучыларга һәм Түбән Кама муниципаль районында күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортларның торак урыннары милекчеләре өчен торак урынын карап тотуга түләү күләмен расларга һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә һәм 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә дип санарга (кушымта)..

2. Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә үзенең гомуми җыелышында торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортларның торак урыннары милекчеләре өчен 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәрге чорга торак урынны карап тоту өчен түләү әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән күләмдә раслана.

3. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә торак урыны өчен түләү билгеләү турында» 2022 елның 28 декабрендәге 938 номерлы карарын 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.Ф. Булатов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның « 27 » декабре
1271 номерлы карары белән расланган
кушымта

## Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучыларга һәм Түбән Кама муниципаль районында күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортларның торак урыннары милекчеләренә торак урынны карап тоту өчен 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр чорга түләү күләме

| т/с | Түләү исеме | Үлчәү берәмлеге | Түбән Кама шәһәре | Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы | Авыл җирлекләре | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Красный Ключ, Афанас | Каенлы, Иске Чишмә, Кызыл Чапчак, Түбән Уратма, Майская Горка, Шәңгәлче, Макаровка | Ширәмәт, Сухрау |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | айга торак урынның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 3,73 | 3,47 | 3,73 | 2,30 | 1,28 |
| 2 | Йорт эчендәге гомуми файдаланудагы урыннарны җыештыру | айга торак урынның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 3,53 | 4,69 | 3,53 | 2,80 | 1,88 |
| 3 | Йорт яны территориясен җыештыру | айга торак урынның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 3,73 | 3,30 | 3,73 | 4,00 | 2,68 |
| 4 | Чүп үткәргечкә хезмәт күрсәтү | айга торак урынның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 2,26 | 1,91 | - | - | - |
| 5 | Торак биналарны агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | айга торак урынның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 4,44 | 3,44 | 4,15 | 3,31 | 3,19 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Йорт эчендәге су-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт ясау | айга торак урынның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 3,20 | 2,58 | 3,20 | 2,17 | 1,80 |
| 7 | Җылылык алмашу җиһазлары белән җиһазландырылган йорт эчендәге су-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт ясау | айга торак урынның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 3,34 | - | - | - | - |
| 8 | Йорт эчендәге үзәк җылыту челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт ясау | айга торак урынның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 3,42 | 1,73 | 3,42 | - | 1,42* |
| 9 | Йорт эчендәге электр челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт ясау | айга торак урынның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 1,09 | 1,28 | 1,09 | 1,07 | 1,17 |
| 10 | Йорт эчендәге газ челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт ясау | айга торак урынның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 0,23 | - | 0,23 | 0,23 | 0,23 |
| 11 | Дератизацияләү (дезинсекцияләү) | айга торак урынның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 0,20 | 0,20 | 0,20 | 0,20 | 0,20 |
| 12 | Наемга түләү (наемга алучыларга) | айга торак урынның гомуми мәйданы сум/кв.м. | Методика нигезендә дифференцияләнгән | | | | |
| 13 | Лифтларга хезмәт күрсәтү | айга торак урынның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 3,40 | 4,60 | - | - | - |
| 14 | Техник чараларга һәм янгын сүндерү һәм төтен суырту системаларына хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау (хезмәт күрсәтү булганда) | айга торак урынның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 1,09 | - | - | - | - |
| 15 | Чүп үткәргечсез күпфатирлы йортлар буенча чүп контейнерларын карап тоту (хезмәт күрсәтү булганда) | айга торак урынның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 0,26 | 0,21 | 0,26 | 0,21 | 0,21 |

Искәрмә:

* тариф Ширәмәт авыл җирлеге буенча билгеләнгән